ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ӘЛМӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа Әлмәле авылы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 гыйнвар 2022 ел №4

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында"

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында" Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән, Яңа Әлмәле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Чүпрәле муниципаль районының Яңа Әлмәле авыл җирлегендә № 1 нче кушымта һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелгән хезмәт хакын 6964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында "гы 2021 ел 29 гыйнвар, 6 нче карарны үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту үз өстемдә кала.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Әлмәле авыл җирлеге башлыгы: Р.Н. Дружков

Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 ел 28 гыйнвар №4 карарына
1 нче кушымта

Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3748,39 |
| 3. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү | 1023,11 |
| 4. Күмү (каберказу һәм күмү) | 2193,18 |
| Барлыгы | 6964,68 |

Чүпрәле муниципаль районы Яңа
Әлмәле авыл җирлеге башкарма
комитетының 2022 ел 28 гыйнвар
№4 карарына
2 нче кушымта

Чүпрәле муниципаль районы Яңа Әлмәле авыл җирлегендә
җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе
исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 395,94 |
| 3. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3352,45 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү | 1023,11 |
| 5. Күмү (каберказу һәм күмү) | 2193,18 |
| Барлыгы | 6964,68 |